**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ
НИЖНЕКАМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Центральнаяя, дом 51,
село Нижняя Каменка, 423114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Үзәк урамы, 51нче йорт,
Түбән Кәминкә авылы, 423114

тел./факс 843962-35-21email: Nkam.Cmn2@tatar.ru

№ 149 30.10.2019 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының
2013 елның 19 ноябрендәге 61 номерлы
«Җир салымы турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 ноябрендәге 61 номерлы «Җир салымы турында» карарына (авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 86 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 104 номерлы, 2018 елның 13 мартындагы 81 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

- 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: « 1) 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылуы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата;
- 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2) 0,3% торак фонд һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);
- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4) 0,15% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару

турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата»;

- 5 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Түбән Кәминкә авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе: Р.Р.Халиков.